**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**«ТЕЛӘНЧЕ-ТАМАК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»**
**МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАР

06 апрель 2016 ел № 6/3

Тукай муниципаль районы «Теләнче-Тамак авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның, муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи бурычларын башкарганда мәнфәгатьләр каршылыгына китерә яки китерергә мөмкин шәхси кызыксыну барлыкка килү турында хәбәр итү тәртибе турында

«Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 12.1 статьясы, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 12 статьясы, «Россия Федерациясенең аерым дәүләт вазыйфаларын, федераль дәүләт хезмәте вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның вазыйфаи бурычларын башкарганда мәнфәгатьләр каршылыгына китерә яки китерергә мөмкин шәхси кызыксыну барлыкка килү турында хәбәр итү тәртибе турында һәм Россия Федерациясе Президентының кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» Россия Федерациясе Президентының 2015 елның 22 декабрендәге 650 номерлы Указының 8 пункты нигезендә муниципаль берәмлек Советы

КАРАР БИРДЕ:

1. Тукай муниципаль районы «Теләнче-Тамак авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның, муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи бурычларын башкарганда мәнфәгатьләр каршылыгына китерә яки китерергә мөмкин шәхси кызыксыну барлыкка килү турында хәбәр итү тәртибе турында нигезләмәне расларга (кушымта нигезендә).
2. Әлеге карарны җирлекнең мәгълүмат стендларында һәм Тукай муниципаль районы порталында игълан итәргә.
3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан мизгелдән үз көченә керә.

Муниципаль берәмлек башлыгы,
Совет рәисе Р.Ш. Нәҗметдинов